

Мордовия тобәгенә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре 2023 елдан башлап комплекслы фәнни экспедициягә чыга башладылар. Оч елга хисапланган бу сәфәр 2023 елда Ләмбрә һәм Ромоданово районнарындагы авылларны ойрәнvдән башланып китте, һәм 15 татар авылында максатчан тикшеренvләр уздырды. 2024 елда Дубёнки, Кочкурово, Рузаевка, Инсар, Кадошкин, Торбеево, Ковылкин, Зубово-Поляна районнарындагы татар авыллары ойрәнелде. Быел исә галимнәр Темников, Атюрьево, Ельники районнарына юл алды. Экспедиция хакында да газета аша хәбәр юлланган иде.

Эшне Темников районыннан башлап жибәрдек. 27 майдан – 30 майга кадәр әлеге районадагы татар авыллары: Тархан, Акаш, Дашка, Янгураз, Адай, Митрәл, Теви, Сухойда булып, бай материал тупланды, бvгенге конгә кадәр халык кvнелендә сакланып калган мирасыбыз барланып, сонгы еллардагы vзгәрешләргә дә игътибар ителде, яна vзенчәлекләр теркәлде.

Бай тарихлы Тархан авылында безне 40 ел мәктәптә укытучы булып эшләгән Супаева Зәйнәп Хоснетдин кызы каршы алды. Ул безгә авыл, мәчет тарихы хакында сойләде, борынгыдан килгән гореф-гадәтләр белән таныштырды. Шунысы куанычлы, авылнын иске мәчет бинасы сакланып калган, аннан ерак тvгел мәһабәт яна мәчет балкый. Мәчет ябылып тормый, аз булса да, жомгаларга йорvче бар, хәтемнәр vткәрелгәндә кеше кvп жыела, читкә китеп урнашкан авыл кешеләре дә даими ярдәм итеп тора. Борынгыдан калган кулъязма, басма мирасыбызга игътибар зур, алар кадерләп саклана. Мәсәлән, Супаева Монирә Мохәммәджан кызы әби-бабалары Әбvбәкер кызы Хәнифә һәм Хосәен улы Садыйк бабайдан калган китаплар белән таныштырды.

Енак авылында бvгенге кондә бары 11 кеше генә гомер итә. Шунысы куанычлы, бетvгә йоз тоткан шушы авылда да без кулъязмалар белән танышу бәхетенә ирештек.

Акаш авылында да инде бvгенге кондә 9 кеше генә кон кvрә. Авыл уртасында ор-яна, ботен унайлыклары: суы, газы, тәһарәт бvлмәсе булган мәчет тозелгән. Мәчет Алия Кузовкинанын шәхси башлангычы һәм, әлбәттә, авыл кешеләре ярдәме белән кvтәрелгән. Хәтемнәр vткәрv очен биредә ботен шартлар тудырылган, шкаф тулы савыт-саба да әзер.
Дашка авылында бvгенге кондә мәчеттә имамлык вазыйфаларын алып барган Дашкин Монир Ибраһим улы белән очрашып, ул безне мәчет тарихы белән таныштырды, иске мәчет хакында да белгәннәрен сойләде, балачак хатирәләрен искә тошерде. Биредә яшәvчеләр белән авылнын бай тарихын да бер кат искә тошердек. Тирә-якны кирпеч белән тәэмин итеп торган кирпеч заводы, анын хужалары хакында да авыл халкы мәгълvматлы, ул елларнын жанлы истәлеге булган бай йорты, заводнын сакланып калган бер олеше дә тарихыбызны онытмаска, хәтердән жуймаска ярдәм итеп тора.
28 май конне Адай авылында эшләдек. Безне мәчет имамы Акчурин Шамил Измаил улы каршы алды. Алия Фәттах кызы Ялышева, ире Шамил Хәлил улы гаиләсе тел галимебез очен дә, фольклорчы, музыка белгече очен дә зур табыш булды: гармунчы Шамил абый белән бик кvп жырлар жырланды, туй йолалары, килен тошерv, кода-кодагыйларны каршы алу вакытындагы инде кызганычка каршы онытыла барган йола-гадәтләр, матур жырларыбыз, кара-каршы әйтешv-жырулар халкыбызнын никадәр бердәм булуын да, талантлы, монлы, искиткеч зиһенле булуы хакында да сойли. Алия апалардагы әбиләреннән калган камзул, калфак исә татар кызларынын нәзәкатьлелеге хакында, шул ук вакытта кулга оста булуларынын да бер кvрсәткече. Адай авылына керv белән Акбулатовлар йорты исә vзенен матурлыгы, милли бизәкләр белән кvз явын алырлык итеп эшләнvе белән дә истә калды. Әлеге йортнын проекты да - йорт хужасы Сәфиулла Алим улыныкы. Әлеге нәселләр арбачылар буларак танылган, авылда гына тvгел, кvрше авылларда да Сәфиулла абыйнын эшләре бар, йорт кvтәрvдә дә ярдәм иткән ул. Шунысы да моһим– ой эчен Акбулатовларнын нәсел шәжәрәсе бизи.
Карай авылы да тозек, караулы булуы белән куандырды. Мәчетләре эшли, имам Сәйфетдинов Рафик Фәрит улы vзе дә белемле, тарихка битараф булмаган кеше. Авыл кешеләре сойләве буенча да, биредә хәтемнәр vтә, дини бәйрәмнәребез онытылмый. Шулай ук яшь буынга да дини тәрбия бирv, телебезгә хормәт тәрбияләv, аны саклау буенча да эш алып барыла. Мәчет тә мирасыбызны барлау, югалтмау очен тырыша. Биредә басма китаплар, дәфтәр, аерым битләрдә язулар, догалыклар, монәжәтләр дәфтәре һ.б. бар. Фольклорчы һәм телче галимнәребез халык вәкилләре белән әнгәмә корып, шушы тобәккә генә хас булган сойләшне ойрәнделәр, тарихи һәм мифологик риваятьләр, хикәятләр, мәкаль-әйтемнәр, жырлар, йола фольклорына караган vрнәкләр, халык уеннары, бәетләр, монәжәтләр һ. б. язып алынды. Сәнгать белгечебез йортларнын тышкы һәм эчке бизәлеше белән кызыксынды, сандык топләрендә ята торган чигvле солге-тастымаллар, карават жәймәләре белән танышты, агач эше, милли киемнәр тегv һ.б. буенча эзләнvләр алып барып, этник мәдәният олкәсен баета торган шактый кызыклы материаллар тапты.
Татар һәм мукшылар бергә бердәм булып гомер иткән Теви, Сухой авылларында да булып, алар да ойрәнv очен бик кызыклы булдылар. Теви авылындагы борынгы мәчет бинасынын сакланып калып, янартылуы, матур гына эшләп килvен ишетv дә кvнелгә рәхәтлек бирде.
Гомумән, әлеге тобәктәге татарлар, олкән буын тарихилыкны саклап калырга, яд итеп яшәргә тырышалар. Шушы эштә безгә чын кvнелдән ярдәм иткән барлык кешеләргә олуг

рәхмәтебезне житкерәбез.
Атюрьево һәм Ельники районнарында да эшебез унышлы булыр, милләтебезнен кvнел жәvһәрләре барланыр дип ышанып калабыз.

**Ләйлә ГАРИПОВА, Әлфия БУЛАТОВА**